**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**21 ноябрь 2025 ел** **№2**

2026 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Бүләк торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлеге Сарлы торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Сарлы авыл җирлеге Бүләк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы тыл хезмәтчәннәреннән, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, махсус хәрби операцияләрдә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларына (әни, әти), Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы гражданнарга бер тапкыр түләүне 2 һәм 3 төркем инвалидларга 250 сум күләмендә билгеләп, үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү автомобилен йөртүченең хезмәтенә түләү, резервуарларга, янгын сүндерү автомобиленә запас частьләр сатып алу);

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (электр товарлары сатып алу, урам яктырткычларын һәм лампаларын алыштыру, урам яктырткычларын ремонтлау, аларга хезмәт күрсәтү хезмәтләре күрсәтү);

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (юлларны һәм территорияләрне кардан чистарту, үлән чабу, чүп җыюда трактор йөртүченең хезмәтләре өчен түләү);

- ремонт, коймалар кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү.).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Сарлы авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Сарлы авыл җирлеге башлыгы И.М.Камалетдинов